**СОВЕТ ТАШЛЫ-КОВАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422716, Республика Татарстан, Высокогорский район, с.Ташлы-Ковали, ул.Школьная, 68

**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАШЛЫ КАВАЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422716, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Ташлы Кавал авылы, Мәктэп урамы, 94

тел./факс 8(84365) 70-4-16,e-mail: Tkvl.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**03 сентябрь 2021 ел** **№ 27**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Ташлы Кавал авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә һәм физик һәм юридик затларның хосусый милкендәге җирләргә кермәгән яшел үсентеләрне кисү тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау районы прокуратурасының 2021 елның 27 маендагы 02-01-26-2021 номерлы таләбе нигезендә, муниципаль норматив-хокукый актларны хокукый анализ һәм мониторинг нәтиҗәләре буенча Россия Федерациясе законнарына Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ташлы Кавал авыл җирлеге Уставына туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ташлы Кавал авыл җирлеге Советы,

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Ташлы Кавал авыл җирлеге Советының 2021 елның 26 мартындагы 20 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Ташлы Кавал авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә һәм физик һәм юридик затларның хосусый милкендәге җирләргә кермәгән яшел үсентеләрне кисү тәртибе турында нигезләмә»нең (Советның 21.04.2021 № 25 карары редакциясендә) 3 бүлегенең 3.6. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«3.6. Эшләр җитештерүгә рөхсәт алганда, аның мәнфәгатьләрендә яшел утыртмалар юкка чыгарыла торган Гариза бирүче, әлеге Нигезләмәгә туры китереп, яшел утыртмаларны кискән өчен компенсация бәясе күләмендә түләүләр кертергә тиеш.»;

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталының рәсми сайтында http://pravo.tatarstan.ru бастырырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе,
Ташлы Кавал авыл җирлеге башлыгы И.И.Хайбуллин